ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**БОЕРЫК** **БОЕРЫК**

07.08.2017 Казан ш. № 190

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының товарларга (эшләргә, хезмәтләргә) дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләр (тарифлар, өстәмәләр, арттырулар) куллану дөреслегенә һәм аларның зурлыкларының нигезле булуына төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазыйфасын үтәү буенча административ регламентын раслау турында» 2015 елның 05 февралендәге 29 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының (алга таба – Дәүләт комитеты) норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатында

б о е р ы к б и р ә м:

1. Дәүләт комитетының 2015 елның 05 февралендәге 29 номерлы боерыгы белән (Дәүләт комитетының 09.03.2016 № 50, 31.01.2017 № 16 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының товарларга (эшләргә, хезмәтләргә) дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләр (тарифлар, өстәмәләр, арттырулар) куллану дөреслегенә һәм аларның зурлыкларының нигезле булуына төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазыйфасын үтәү буенча административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

боерыкның аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының товарларга (эшләргә, хезмәтләргә) дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, арттыруларны) куллануның дөрес һәм аларның зурлыкларының нигезле булу-булмавы өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салына

торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкару буенча административ регламентын раслау турында»;

боерыкның беренче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының товарларга (эшләргә, хезмәтләргә) дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, арттыруларны) куллануның дөрес һәм аларның зурлыкларының нигезле булу-булмавы өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкару буенча административ регламентын расларга.».

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2015 елның 05 февралендәге 29 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының товарларга (эшләргә, хезмәтләргә) дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләр (тарифлар, өстәмәләр, арттырулар) куллану дөреслегенә һәм аларның зурлыкларының нигезле булуына төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазыйфасын үтәү буенча административ регламентына (алга таба – Административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Административ регламентның аталышындагы һәм кушымталарның нумерацияле баш исемнәрендәге тиешле килеш кушымчаларында кулланылган «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының товарларга (эшләргә, хезмәтләргә) дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләр (тарифлар, өстәмәләр, арттырулар) куллану дөреслегенә һәм аларның зурлыкларының нигезле булуына төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт вазыйфасын үтәү буенча административ регламенты» сүзләрен, тиешле килеш кушымчаларында кулланып, «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының товарларга (эшләргә, хезмәтләргә) дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, арттыруларны) куллануның дөрес һәм аларның зурлыкларының нигезле булу-булмавы өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкару буенча административ регламенты» сүзләренә алмаштырырга;

1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Административ регламент (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының товарларга (эшләргә, хезмәтләргә) дәүләт тарафыннан җайга салынырга тиешле бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, арттыруларны) куллануның дөрес һәм аларның зурлыкларының нигезле булу-булмавы өлешендә дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә төбәк дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкару буенча әлеге административ регламентының административ процедураларының һәм административ гамәлләренең вакытларын һәм эзлеклелеген билгели.

Дәүләт функциясенең аталышы: «Дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләр (тарифлар) өлкәсендә товарларга (эшләргә, хезмәтләргә) дәүләт тарафыннан җайга салына торган бәяләрне (тарифларны, өстәмәләрне, арттыруларны) куллануның дөрес һәм аларның нигезле булу-булмавы өлешендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) (алга таба, тиешенчә, – дәүләт функциясе, төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге)).»;

1.3 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«1.3. Дәүләт комитеты тарафыннан дәүләт функциясе түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 05.12.1994, № 32, 3301 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясенең Административ хокук бозулар турында кодексы (алга таба – РФ КоАП) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 07.01.2002, № 1 (1 өл.), 1 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Су кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 05.06.2006, № 23, 2381 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Урман кодексы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 11.12.2006, № 50, 5278 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Табигый монополияләр турында» 1995 елның 17 августындагы 147-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 21.08.1995, № 34, 3426 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Калдыклар турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, № 26, 29.06.1998, 3009 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 05.04.1999, № 14, 1667 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 31.03.2003, № 13, 1177 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында» 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 03.01.2005, № 1 (1 өлеше), 36 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт контрольлеген (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольлекне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 29.12.2008, № 52 (1 өл.), 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дару чаралары әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 19.04.2010, № 16, 1815 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Җылы белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ

номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 02.08.2010, № 31, 4159 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Транспорт чараларын техник карау турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 1 июлендәге 170-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 04.07.2011, № 27, 3881 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Юридик затларның аерым төрләре тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алулар турында» 2011 елның 18 июлендәге 223-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 25.07.2011, № 30 (1 өл.), 4571 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлү турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 12.12.2011, № 50, 7358 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 30.12.2013, № 52 (1 өлеше), 7007 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 28 февралендәге 221 номерлы Указы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 06.03.1995, № 10, 859 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә үзйөрешле машиналарның һәм башка техника төрләренең техник торышына дәүләт күзәтчелеге турында» 1993 елның 13 декабрендәге 1291 номерлы карары (Россия Федерациясе Президенты һәм Хөкүмәте актлары җыелмасы, 20.12.1993, № 51, 4943 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 13.03.1995, № 1, 997 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Газга һәм аны җитештерү чималына бәяләрне дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 15 апрелендәге 332 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 24.04.1995, № 17, 1539 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә торак фондын дәүләт исәбенә алу турында» 1997 елның 13 октябрендәге 1301 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, № 42, 20.10.1997, 4787 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе территориясендә газга бәяләрне, аны транспортлау хезмәтләренә тарифларны һәм газкулланучы җайланманы газ бүлү челтәрләренә технологик тоташтырганга түләүне дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2000 елның 29 декабрендәге 1021 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 08.01.2001, № 2, 175 ст.,

кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергиясен тапшыру хезмәтләреннән дискриминацияләнмәгән рәвештә файдалану һәм мондый хезмәтләрне күрсәтү кагыйдәләрен, Электр энергетикасында оператив-диспетчерлык идарәлеге хезмәтләреннән дискриминацияләнмәгән рәвештә файдалану һәм мондый хезмәтләрне күрсәтү кагыйдәләрен, Күмәртәләп сату базарының сәүдә системасы администраторы хезмәтләреннән дискриминацияләнмәгән рәвештә файдалану һәм мондый хезмәтләрне күрсәтү кагыйдәләрен һәм Электр энергиясен кулланучыларның энергияне кабул итү җайланмаларын, электр энергиясен җитештерү буенча объектларны, шулай ук челтәр оешмаларыныкы һәм башка затларныкы булган электр хуҗалыгы объектларын электр челтәрләренә технологик тоташтыру кагыйдәләрен раслау турында» 2004 елның 27 декабрендәге 861 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 27.12.2004, № 52 (2 өлеше), 5525 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Транспорт терминалларында, портларда, аэропортларда табигый монополия субъектларының хезмәтләренә һәм эчке су юллары инфраструктурасыннан файдалану хезмәтләренә бәяләрне (тарифларны, җыемнарны) дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2008 елның 23 апрелендәге 293 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 28.04.2008, № 17, 1887 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә бәя хасил итү нигезләре һәм тарифларны, өстәмәләрне һәм чик дәрәҗә индексларын җайга салу тәртибе турында» 2008 елның 14 июлендәге 520 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 21.07.2008, № 29 (2 өл.), 3518 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендәге башкарма хакимият органнарының табигый монополия субъектлары эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салуны һәм контрольдә тотуны гамәлгә ашыруда катнашуы хакында» 2008 елның 10 декабрендәге 950 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 15.12.2008, № 50, 5971 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гомер өчен зарури һәм әһәмиятле дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларына бәяләрне дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2010 елның 29 октябрендәге 865 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 08.11.2010, № 45, 5851 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Транспорт чараларына техник карау үткәрү турында» 2011 елның 5 декабрендәге 1008 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 12.12.2011, № 50, 7397 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2011 елның 29 декабрендәге

1178 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 23.01.2012, № 4, 504 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергиясен ваклап сату базарларының вазыйфалавы, электр энергиясен куллану режимын тулысынча һәм (яки) өлешчә чикләү турында» 2012 елның 4 маендагы 442 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 04.06.2012, № 23, 3008 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 29.10.2012, № 44, 6022 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 20.05.2013, № 20, 2500 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт тарафыннан җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә дәүләт контрольлеге (күзәтчелеге), шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларын көчен югалткан дип тану турында» 2013 елның 27 июнендәге 543 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 08.07.2013, № 27, 3602 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бердәм тикшерүләр реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 11.05.2015, № 19, 2825 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан документларга һәм (яисә) мәгълүматларга, шул исәптән электрон рәвештә, шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмаларга гарызнамәләр җибәрү һәм аларны түләүсез нигездә алу турында» 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары (РФ законнар җыентыгы, 25.04.2016 № 17, 2418 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклары белән эш итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 06.06.2016, № 23, 3331 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүгә карата ризасызлыклар тапшыру һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 10 февралендәге № 166 карары) (Хокукый мәгълүматның рәсми

интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 14 февраль, бастырып чыгару номеры: 0001201702140002);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Тикшерүләрне оештырганда һәм үткәргәндә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында шушы документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалардан сорала һәм алына торган документлар һәм (яки) мәгълүматлар исемлеген раслау турында 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы боерыгы (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2016, № 18, 2647 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контрольлегенен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольлекне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру турында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (Российская газета, № 85, 14.05.2009, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы (Республика Татарстан, № 110, 30.05.2008, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Тоткарланган транспорт чараларын махсуслаштырылган тукталыш урынына күчерү, аларны саклау, кайтарып бирү, аларны күчерү һәм саклау чыгымнарын түләү тәртибе турында» 2012 елның 17 маендагы 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Республика Татарстан, № 100, 26.05.2012, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Республика Татарстан, № 186, 20.12.2014);

«Россия Федерациясендә автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты белән пассажирларны һәм багажны даими ташуларны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Республика Татарстан, № 188, 29.12.2015, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 04.08.2010, № 29, 1195 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында транспорт чараларын техник карауны үткәрү өчен чик дәрәҗәдә түләү күләмнәрен һәм техник карау талоны дубликатын рәсмиләштерүгә чик дәрәҗәдә чыгымнар күләмен билгеләү турында» 2011 елның 27 декабрендәге

1079 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 31.01.2012, № 8, 0296 ст.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр җиткерүчеләр тарафыннан социаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен раслау турында» 2014 елның 29 декабрендәге 1053 номерлы карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 30.01.2015, № 7-8, 0201 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).»;

1.7 пунктының 1.7.3 пунктчасында:

дүртенче абзацны төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «(бу абзацтагы таләп 2017 елның 1 июленнән гамәлдә була)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.8 пунктның 1.8.1 пунктчасындагы тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« – билгеләнгән тәртиптә Дәүләт комитетына юридик затка, шәхси эшкуарга карата тикшерүне планлы тикшерүләрнең еллык планыннан төшереп калдыру турында гариза бирергә, әгәр дә тикшерүнең планлы тикшерүләрне үткәрүнең еллык планына кертелүе № 294-ФЗ Федераль законның 26.1 статьясындагы нигезләмәләрне бозып гамәлгә ашырылган дип уйласалар.»;

2.7 пунктка түбәндәге эчтәлекле кызыл юл өстәргә:

«Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында мондый чаралар күрелгән көннән соң ун көн эчендә Дәүләт комитеты язмача рәвештә хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшкуарга хәбәр итәргә бурычлы.»

3 бүлектә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Үтәлешен Дәүләт комитеты тикшереп тора торган, юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата белдерелә торган зарури таләпләрнең исемлеге, эшчәнлекнең зарури таләпләр куела торган төрләрен, зарури таләпләрне билгели торган таләпләрнең, норматив хокукый актларның төрләрен күрсәтеп, 1 нче таблицада китерелде.»;

1 таблицада:

15 пунктын төшереп калдырырга;

26 пунктның 4 графасында «Күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль законның» сүзләрен «Кадастр эшчәнлеге турында» 2007 елның 24 июлендәге 221-ФЗ номерлы Федераль законның» сүзләренә алмаштырырга»;

түбәндәге эчтәлекле 3.2-3.3 пунктларын өстәргә:

«3.2. Юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан зарури таләпләрнең бозылуын кисәтү, зарури таләпләрне бозуларга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны юкка чыгару максатларында Дәүләт комитеты ел саен

үзе тарафыннан расланучы бозуларны профилактикалау программасы нигезендә дәүләт тарафыннан җайга салынучы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә зарури таләпләрнең бозылуын профилактикалау буенча чараларны гамәлгә ашыра.

3.3. Дәүләт комитетында килгән мөрәҗәгатьләрдә һәм гаризаларда (авторлыгы расланмаган мөрәҗәгатьләрдән һәм гаризалардан тыш), дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүматларда бәян ителгән зарури таләпләрне бозуларның әзерләнеп ятуы яисә бозылу билгеләре хакында мәгълүматлар булганда, әгәр дә юридик зат, шәхси эшкуар элек тиешле таләпләрне бозган өчен җаваплылыкка тартылмаган булса, Дәүләт комитеты юридик затка, шәхси эшкуарга зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү белдерә һәм юридик затка, шәхси эшкуарга зарури таләпләрнең үтәлүен тәэмин итү буенча чаралар күрергә һәм бу хакта шул кисәтүдә билгеләнгән чорда Дәүләт комитетына хәбәр итәргә тәкъдим итә.

Зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүне төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүгә ризасызлыклар белдерүе һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү тәртибе Дәүләт комитеты тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

4 бүлекнең 2 таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| «№№ п/п | Тикшерү үткәрү өчен күрсәтелә торган документ | Документ рәвешен билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Тикшерү үткәргәндә барча юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан күрсәтелә торган документлар. | |
| 1.1 | Гражданинның, шәхси эшкуарның, юридик затның законлы вәкиленең, аларның вәкаләтле вәкилләренең шәхесен таныклаучы документлары. | |
| 1.2 | Юридик затның, шәхси эшкуарның яисә гражданинның мәнфәгатьләрен белдерүче затның вәкаләтләрен раслаучы документлар. | |
| 1.3 | Структур бүлекчәләр турында нигезләмәләр. | |
| 1.4 | Предприятиенең исәпкә алу сәясәте турында нигезләмәләр. | |
| 1.5 | Коммуналь инфраструктура системаларын эксплуатацияләү хокукын раслый торган документлар (аренда, субаренда шартнамәләре, концессия килешүләре, төп чараларны кабул итү-тапшыру актлары һ.б.). | 21.01.2003 № 7 РФ Госкомстат карары |

| | | |
|---|---|---|
| 1.6 | Төп чаралар исемлеге, эксплуатациягә кертү һәм чыгару турындагы мәгълүматлар белән, аларның баланс бәясе һәм файдалы куллануның билгеләнгән чорлары. Төп чараларны яңадан бәяләү турында боерык. Төп чаралар (ОС-6, ОС-6а, ОС-6б) объектларын (шул исәптән арендага алынганнарын, концессия буенча кабул ителгәннәрен) исәпкә алуның инвентарь карточкалары яисә бүтән төрле беренчел исәпкә алу документлары. | 21.01.2003 № 7 РФ Госкомстат карары;<br>24.11.2015 № 563 Росстат боерыгы;<br>13.10.2003 № 91-н РФ Финанс министрлыгы боерыгы |
| 1.7 | Төп кенәгә (өлешчә, тикшернүне гамәлгә ашыручы затларның ихтыяры буенча). | 30.03.2015 № 52н РФ Финанс министрлыгы боерыгы |
| 1.8 | Бухгалтерлык хисапнамәсе:<br>– бухгалтерлык балансы (№ 1 форма), тикшерә торган чорга ИФНС РФ тамгасы белән;<br>– финанс нәтиҗәләре турында хисап (№ 2 форма), хезмәтләрнең төрләре буенча тәгаенләштереп;<br>– капитал үзгәрешләре турында хисап (№ 3-еллык форма);<br>– акча хәрәкәте турында хисап (№ 4-еллык форма);<br>– еллык балanска аңлатма язуы;<br>– әйләнеш-сальдо исемлекләре, исәп-хисапларга анализ (таләп буенча). | 06.07.1999 № 43н РФ Финанс министрлыгы боерыгы;<br>02.07.2010 № 66н РФ Финанс министрлыгы боерыгы;<br>06.10.2008 № 106н РФ Финанс министрлыгы боерыгы |
| 1.9 | Оешманың исәпкә алу сәясәте турында боерыкның билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәсе. | |
| 1.10 | Тармактагы методика күрсәткечләре (электр һәм җылылык энергиясе; җибәрелгән су – 6-в; агынты суларны чыгару – 6-к; кайнар су белән тәэмин итү хезмәтләре – 6-ГВС; каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү – 6-гомуми һ.б.) нигезендә үзкыйммәтне калькуляцияләү хисапнамәләре. | 23.02.1999 № 9 РФ Госстрой карары |
| 1.11 | Шартнамәләр:<br>– товарларны (эшләрне, хезмәтләрне), шул исәптән бәяләре җайга салынырга тиешле җиткерүчеләр белән;<br>– бәяләре законнарда билгеләнә торган тәртиптә куела торган товарларны җиткерүгә, хезмәтләрне күрсәтүгә, эшләрне башкаруга (шул исәптән дәүләти (муниципаль) ихтыяҗлар өчен) юридик затлар, шәхси эшкуарлар, катрагентлар (абонентлар, субабонентлар) белән төзелгән. | РФ Хөкүмәтенең 2013 елның 29 июлендәге № 645 карары |
| 1.12 | Җайга салуның карала торган чоры буенча кулланучыларның коммуналь энергия ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителгәнлеген күрсәтеп, һәр абонент буенча ресурсның шартнамә күләмен күрсәтеп, коммуналь ресурс белән тәэмин итү чыганагы кисемендә һәр җайга салынучы эшчәнлек төре буенча абонентлар исемлеге. Җайга салуның карала торган хисап чорында һәр җайга салынучы эшчәнлек төре буенча абонентлар исемлегеннән чыккан оешмалар исемлеге. | |

| | | |
|---|---|---|
| 1.13 | Бәяләре җайга салынырга тиешле товарларны китергән, хезмәтләр күрсәтелгән, эшләр башкарылган өчен исәп-хисап ясалуларны таныклый торган түләү документлары (исәп-хисап фактуралары, накладнаялар, башкарылган эшләрнең актлары, бәяләр килештерү беркетмәләре). | 25.12.1998 № 132 РФ Госкомстат карары;<br>18.08.1998 № 88 Госкомстат карары;<br>РФ Хөкүмәтенең 2011 елның 26 декабрендәге № 1137 карары;<br>РФ Хөкүмәтенең 2016 елның 3 февралендәге № 58 карары |
| 1.14 | Сатып алулар турында нигезләмә. Законнарда билгеләнгән тәртиптә товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алуларны үткәрүне раслый торган документлар (Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда). | |
| 2. | Тарифларны хисаплаганда кабул ителгән аерым чыгым статьялары буенча чыгымнарны нигезләү өчен өстәмә (тикшерүдә катнашучы затлар ихтыяры буенча тапшырыла). | |
| 2.1 | Тарифлар гамәлдә булган чорда оешманың товарларны һәм хезмәтләрне сату күләмнәрен раслый торган документлары, шәхси  ихтыяҗлар һәм челтәрләрдәге югалтулар өчен коммуналь ресурслар чыгымын нигезләп. | 25.12.1998 № 132 РФ Госкомстат карары;<br>РФ Хөкүмәтенең 2011 елның 26 декабрендәге № 1137 карары |
| 2.2 | Тарифлар гамәлдә булган чорда чималга, төп һәм ярдәмче материалларга (шул исәптән ягулыкка һәм ягулык-майлау материалларына) чыгымнарны раслый торган документлар, төп чараларны төзекләндерү сарыфларын аерып чыгарып, түбәндәгеләрне дә кертеп:<br>– материаллар китертүгә шартнамәләр реестры;<br>– тарифлар гамәлдә булган чорга агымдагы бәяләр белән исәп-хисап фактуралары;<br>– регламентлаучы документларны күрсәтеп, материалларны сарыф итү нормалары һәм нормативлары. | 25.12.1998 № 132 РФ Госкомстат карары;<br>РФ Хөкүмәтенең 2011 елның 26 декабрендәге № 1137 карары |
| 2.3 | Тарифлар гамәлдә булган исәп-хисап чорында хезмәткә түләү фондын раслый торган документлар:<br>– оешма хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча дәрәҗәләрне (разрядларны) күрсәтеп, штат расписаниесе;<br>– коллектив шартнамәсе (хезмәткәрләрне һәм җитәкчеләрне пермияләү турындагы нигезләмәләр белән);<br>– хезмәткәрләрнең норматив санын хисаплау. | 05.01.2004 № 1 РФ Госкомстат карары |
| 2.4 | Федераль дәүләт статистика хезмәте тарафыннан раслана торган дәүләт статистика хисапнамәсе формалары (соңгы 2 ел өчен һәм соңгы хисап датасы өчен):<br>– хезмәткәрләрнең саны, хезмәт хакы һәм хәрәкәте турында белешмәләр;<br>– эшчәнлек төрләре буенча хезмәткәрләрнең саны һәм хезмәт хакы турында белешмәләр;<br>– инвестиция эшчәнлеге турында белешмәләр;<br>– төп фондларның (акчаларның) һәм башка финанска карамаган активларның булуы һәм хәрәкәте турында белешмәләр. | 02.08.2016 № 379 Росстат боерыгы;<br>04.09.2014 № 548 Росстат боерыгы;<br>26.06.2017 № 428 Росстат боерыгы |

| | | |
|---|---|---|
| 2.5 | Бердәм социаль салым буенча регрессив шкаланы исәпкә алып, тарифлар гамәлдә булган исәп-хисап чорына социаль ихтыяҗлар өчен күчерелгән акча күләмен раслый торган документлар.<br>Травматизм өчен иминият кертемнәренең күләме турында белдерүнамә. | 21.12.1998 № 64н РФ Финанс министрлыгы боерыгы |
| 2.6 | Сатып алынучы коммуналь ресурсларга чыгымнарны раслый торган документлар:<br>– еллык күләмнәр турында белешмәләр;<br>– түләгәнлекне раслый торган түләү документлары. | 25.12.1998 № 132 РФ Госкомстат карары;<br>РФ Хөкүмәтенең 2011 елның 26 декабрендәге № 1137 карары |
| 2.7 | Төп чараларны ремонтлауга чыгымнар бүлеп, тарифлар гамәлдә булганисәп-хисап чорына җитештерү холкындагы эшләргә һәм хезмәтләргә чыгымнарны раслый торган документлар, түбәндәгеләрне дә кертеп:<br>– аталган чыгымнарны тәгаенләштерүне;<br>– факттагы чыгымнар турында хисап;<br>– эшләр башкаруга шартнамәләр;<br>– түләгәнлекне раслый торган түләү документлары. | |
| 2.8 | Тарифлар гамәлдә булган чорда төп фондларның амортизация күләмен раслый торган документлар, түбәндәгеләрне дә кертеп:<br>– төп чараларны кертү һәм чыгару даталарын күрсәтеп, төп чараларны исәпкә алу һәм амортизацияләр күчерү исемлеге;<br>– соңгы 2 ел өчен амортизация күчерүләрдән файдалану турында хисап;<br>– тарифлар гамәлдә булган чорга яңадан кертелү торган объектлар буенча амортизация хисаплау;<br>– төп чараларны яңадан бәяләү турында боерыклар;<br>– мөлкәтнең базар бәясен бәяләү турында бәяләмә;<br>– җайга салынучы чордан соң килүче чорга һәм тарифлар гамәлдә булган исәп-хисап чорына амортизация хисаплау туктатылган объектларның исемлеге һәм аларның бәясе;<br>– төп чараларны гамәлдән чыгару турында боерыклар;<br>– анализлана торган чорга гамәлдән чыгарырга планлаштырыла торган объектлар исемлеге һәм аларның бәясе. | 21.12.1998 № 64н РФ Финанс министрлыгы боерыгы |

| | | |
|---|---|---|
| 2.9 | Тарифлар гамәлдә булган исәп-хисап чорында ремонтка сарыфларны раслый торган документлар, түбәндәгеләрне дә кертеп:<br>– җитештерү җайланмаларының техник торышы турында экспертиза бәяләмәләре, технадзор һәм башка органнар күрсәтмәләре, үткәрелә торган ремонт эшләренә җитешсезлек исемлекләре;<br>– подрядчы оешмалар белән, шул исәптән сатулашуларның нәтиҗәсе буенча төзелгән шартнамәләр (гамәлдәге законнар нигезендә үткәрелгән сатулар турында мәгълүмат тапшырып);<br>– башкарылган ремонт актлары;<br>– түләгәнлекне раслый торган түләү документлары;<br>– фактта башкарылган ремонт эшләре турында хисап, һәр җайга салынучы чорның 3 елына һәм яртыеллыкларына бүлгәләп, күләмнәрен һәм эшләрнең бәяләрен һәм әлеге максатларга тарифта исәпкә алынган чараларны күрсәтеп. | 25.12.1998 № 132 РФ Госкомстат карары;<br>РФ Хөкүмәтенең 2011 елның 26 декабрендәге № 1137 карары |
| 2.10 | Тарифлар гамәлдә булган чорга иминиятләштерүгә чыгымнарны раслый торган документлар, түбәндәгеләрне дә кертеп:<br>– иминиятләштерү шартнамәләре;<br>– иминиятләштерелгән мөлкәт исемлеге;<br>– иминият полислары;<br>– иминият түләүләре турында хисап. | РФ Хезмәт министрлыгының 18.07.2001 № 56 карары;<br>Куркыныч объектта авария нәтиҗәсендә салынган зыян өчен куркыныч объект хуҗасының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминиятләштерү кагыйдәләре турында нигезләмә (Россия Банкының 28.12.2016 № 574-П боерыгы белән расланган) |
| 2.11 | Мөлкәтне, җайланманы, җир кишәрлекләрен арендалауга чыгымнарны раслый торган документлар:<br>– милекчеләр (арендага бирүчеләр) белән шартнамәләр;<br>– тарифлар гамәлдә булган исәп-хисап чорына аренда түләүләрен хисаплау;<br>– түләгәнлекне раслый торган түләү документлары. | 25.12.1998 № 132 РФ Госкомстат карары;<br>РФ Хөкүмәтенең 2011 елның 26 декабрендәге № 1137 карары |
| 2.12 | Салымнар күләме турында таныклый торган документлар (салым базасын һәм салым ставкаларын нигезләп). Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыклары белән раслана торган формалар буенча хисапнамәләр (соңгы 2 ел өчен һәм соңгы хисап датасына):<br>– оешмаларның мөлкәтенә салым буенча салым декларациясе;<br>– иминият кертемнәре буенча салым декларациясе;<br>– табышка салым буенча салым декларациясе;<br>– су салымы буенча салым декларациясе;<br>– транспорт салымы буенча салым декларациясе;<br>– җир салымы буенча салым декларациясе;<br>– башка салымнар, кертемнәр һәм җыемнар буенча салым декларацияләре һәм хисапнамәләр. | 24.11.2011 № ММВ-7-11-895 РФ ФСХ боерыгы;<br>05.11.2013 № ММВ -7-11/478@ Россия ФСХ боерыгы;<br>Россия Финанс министрлыгының 19.12.2016 № 237н боерыгы;<br>19.10.2016 № ММВ-7-3/572@ Россия ФСХ боерыгы;<br>05.12.2016 № ММВ-7-21/668@ Россия ФСХ боерыгы;<br>09.11.2015 N ММВ-7-3/497@ Россия ФСХ боерыгы;<br>28.10.2011 № ММВ-7-11/696@ РФ ФСХ боерыгы;<br>04.07.2014 № ММВ-7-3/353@ РФ ФСХ боерыгы |

| | | |
|---|---|---|
| 2.13 | Тарифлар гамәлдә булган исәп-хисап чорына әйләнә-тирә мохитне пычратуга түләү исәбен раслый торган документлар, ташландыкларның (урнаштыруның) фактик күләмнәрен һәм гамәлдәге ставкаларны күрсәтеп. Түләгәнлекне раслый торган түләү документлары. Салым декларациясе һәм әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты буенча исәпнамәләр. | 23.02.1999 № 9 РФ Госстрой карары;<br>25.12.1998 № 132 РФ Госкомстат карары;<br>РФ Хөкүмәтенең 2011 елның 26 декабрендәге № 1137 карары;<br>Россия Табигать министрлыгының 09.01.2017 № 3 боерыгы |
| 2.14 | Цех, гомумҗитештерү, гомумхуҗалык чыгымнарын раслый торган (чыгым элементлары буенча аларны тәгаенләштереп һәм хезмәт төрләре буенча бүлгәләп (предприятиенең исәпкә алу сәясәте буенча)), шулай ук аларның икътисадый нигезләнешләрен теркәп, тарифлар гамәлдә булган исәп-хисап чорына аерым элементлар буенча шартнамәләр исемлеген һәм чыгымнарның исәпнамәләрен кертеп):<br>– банк хезмәтләренә чыгымнар;<br>– элемтә чыгымнары;<br>– почта хезмәтләре чыгымнары;<br>– объектларны саклау чыгымнары;<br>– янгын сагы хезмәтләренә чыгымнар;<br>– кадрларны әзерләү, яңадан әзерләү һәм аларның квалификацияләрен күтәрү чыгымнары;<br>– командировка чыгымнары;<br>– вәкиллек чыгымнары;<br>– нормаль хезмәт шартлары һәм куркынычсызлык техникасы белән тәэмин итү чыгымнары;<br>– идарәче компанияне (административ-техник персоналны) асрау чыгымнары;<br>– юридик, консультатив, мәгълүмати, аудиторлык хезмәтләренә чыгымнар;<br>– бүтән төрле чыгымнар (тәгаенләштереп). | |
| 2.15 | Тарифларны (өстәмәләрне) билгеләгәндә исәпкә алынмаган, икътисадый яктан нигезләнгән, тотылган чыгымнарны, шул исәптән җайга салуның исәп-хисап чоры дәвамында кулланыла торган продукциягә объектив һәм планлаштырылмаган рәвештә арткан бәяләргә бәйле чыгымнарны раслый торган документлар, фактта тотылган чыгымнарны икътисадый нигезләп, түбәндәгеләрне дә кертеп:<br>– кулланыла торган продуктларның (хезмәтләрнең) фактик күләмнәренең планда каралганнан артып китү сәбәпләре;<br>– кулланыла торган продуктларга (хезмәтләргә) бәяләрнең планда каралганга караганда чагыштырмача артуын раслау;<br>– планда күрсәтелгән чыгымнарны артып китә торган фактик чыгымнарны финанслау чыганагы;<br>– әлеге заем чараларына хезмәт күрсәтүгә бәйле өстәмә чыгымнарны исәпләү. | |
| 2.16 | Алдагы җайга салу чорына тарифта исәпләнгән, алынган табыштан фактик файдалану турында хисап. | 02.07.2010 № 66н РФ Финанс министрлыгы боерыгы |

| | | |
|---|---|---|
| 2.17 | Тарифлар гамәлдә булган исәп-хисап чорында табыш күләмен раслый торган документлар, түбәндәгеләргә юнәлдерелгән булырга тиеш:<br>– җитештерүне (социаль) үстерү программасын теркәп, җитештерүне (социаль) үстерүгә, шулай ук җитештерүне (социаль) үстерүгә чыгымнарны тәгаенләштерүгә һәм исәпләүгә;<br>– бүләкләүгә, шул исәптән коллектив шартнамәсе һәм тармактагы тариф килешүләре нигезләмәләренә сылтама ясап, фактта түләүләрне алган хезмәткәрләр санын күрсәтеп, социаль холыклы түләүләр исәпләмәсенә;<br>– дивидендлар түләүгә, алдагы 3 ел өчен фактта түләнгән дивидендларны һәм предприятиенең дивиденд сәясәтен (ул булган очракта) кертеп;<br>– «бүтән максатларга» (чыгымнарны тәгаенләштереп, тарифлар гамәлдә булган исәп-хисап чорына шартнамәләр исемлеген кертеп).<br>Тарифлар гамәлдә булган исәп-хисап чорына табыш хисабыннан түләнә торган салымнарны хисаплау, шул исәптән бухгалтерлык һәм салым исәбенә алу максатларында исәпкә алына торган амортизация сумнарын күрсәтеп, табышка салым хисаплау. | |
| 2.18 | Оешманың җитештерү программасына кертелә торган инвестиция ресурсларыннан файдалану турында хисап. | |
| 3. | Җылы белән тәэмин итү һәм җылылык энергиясен тапшыру өлкәсендә эшчәнлек башкаручы оешмалар өчен өстәмә. | |
| 3.1 | Кулланучыларның төркемнәренә бүлгәләп, хисап чорына җылылык яисә электр энергиясе буенча фактик баланс. | |
| 3.2 | Ягулык чыгымын хисаплау буенча белешмәләр, ш.и.:<br>– ягулык китертүгә шартнамәләр;<br>– түләгәнлекне раслый торган исәп-хисап фактуралары. | 25.12.1998 № 132 РФ Госкомстат карары;<br>РФ Хөкүмәтенең 2011 елның 26 декабрендәге № 1137 карары |
| 3.3 | Мөрәҗәгать итүче технологик тоташтыру өчен түләгәндә челтәр оешмасының төшеп калучы табышларын раслаучы документлар. | |
| 3.4 | Җылылык челтәрләренең баланс мөнәсәбәтен чикләү актлары, якларның эксплуатация җаваплылыгын чикләү актлары. | |
| 3.5 | Һәр челтәр кишәрлегенең диаметрын һәм озынлыгын күрсәтеп, җылылык энергиясенең һәр чыганагыннан (котельныйдан) кулланучыларга кадәр (җылы белән тәэмин итү шартнамәләре буенча абонентлар исемлеге нигезендә) җылылык челтәрләре схемасы. | |
| 3.6 | Җылы белән тәэмин итү системаларына тоташтыру (технологик тоташтыру) турында шартнамәләр. | |
| 3.7 | Җылы белән тәэмин итү системаларына объектларны тоташтыру (технологик тоташтыру) шартлары. | |

| | | |
|---|---|---|
| 3.8 | Җылы белән тәэмин итү системаларына тоташтыру (технологик тоташтыру) буенча чаралар исемлеге. | |
| 3.9 | Мәйдан эче һәм (яисә) йорт эче челтәрләренең һәм җайланманың әзерлеге турында акт. | |
| 3.10 | Җылы белән тәэмин итү системаларына тоташтыру (технологик тоташтыру) өчен түләү күләме. | |
| 3.11 | Объектны тоташтыру (технологик тоташтыру) турында акт. | |
| 3.12 | Баланс мөнәсәбәтен чикләү турында акт. | |
| 4. | Су белән тәэмин итү һәм су бүлү өлкәсендә эшчәнлек башкаручы оешмалар өчен өстәмә. | |
| 4.1 | Сууткәргеч (аерым сууткәргеч челтәренең), канализация (аерым канализация челтәренең) эше турында (соңгы 3 ел өчен) белешмәләр. | 17.07.2015 № 327 Росстат боерыгы;<br>15.08.2016 № 427 Росстат боерыгы |
| 4.2 | Салкын су белән тәэмин итү һәм су бүлү буенча үзәкләштерелгән системаларга тоташтыру (технологик тоташтыру) турында шартнамәләр. | РФ Хөкүмәтенең 2013 елның 29 июлендәге № 645 карары |
| 4.3 | Объектларны салкын су белән тәэмин итү һәм су бүлү буенча үзәкләштерелгән системаларга тоташтыру (технологик тоташтыру) шартлары. | |
| 4.4 | Салкын су белән тәэмин итү һәм су бүлү буенча үзәкләштерелгән системаларга тоташтыру (технологик тоташтыру) чаралары исемлеге. | |
| 4.5 | Салкын су белән тәэмин итү һәм су бүлү буенча үзәкләштерелгән системаларга тоташтыру (технологик тоташтыру) өчен түләү күләме. | |
| 4.6 | Объектны тоташтыру (технологик тоташтыру) турында акт. | |
| 5. | Бүлүче электр челтәрләренә технологик тоташтыруны гамәлгә ашыручы челтәр оешмалары өчен өстәмә. | |
| 5.1 | Челтәр оешмасының бүлүче электр челтәрләренә энергияне кабул итү җайланмаларын технологик тоташтырган өчен челтәр оешмасына заявкалар. | |
| 5.2 | Кулланучыларның энергияне кабул итү җайланмаларын технологик тоташтыруга техник шартлар. Техник шартларны үтәү турында акт. Электр челтәрләренә технологик тоташтыруны гамәлгә ашыру турында шартнамәләр. | |
| 5.3 | Электр челтәрләренең баланс мөнәсәбәте буенча чикләү акты. Якларның эксплуатация җаваплылыгын чикләү акты. | |
| 5.4 | Технологик тоташтыруны гамәлгә ашыру турында акт. | |

| | | |
|---|---|---|
| 6. | Транспорт хезмәтләре өлкәсендә эшчәнлек башкаручы оешмалар өчен өстәмә. | |
| 6.1 | Билет-исәпкә алу кәгазьләре. | |
| 6.2 | Халыкка транспорт хезмәтләре күрсәтү буенча вәкаләтле орган тарафыннан расланган заказ Ташуларның заказчысы белән шартнамә. | |
| 6.3 | Лизинг түләүләре графигы белән хәрәкәт составы сатып алуга гамәлдәге лизинг шартнамәләре. Лизинг түләүләрен түләү фактын раслаучы документлар. | |
| 6.4 | Маршрутларның исемлеге, маршрутларның паспортларының һәм маршрутларның расписаниесе күчермәләре. | |
| 6.5 | Транспорт өлкәсендә күзәтү буенча контрольлек органнарының хәрәкәт иминлегенә һәм тимер юл транспортын эксплуатацияләүгә куркыныч тудыра торган җитешсезлек очракларын ачыклау өлешендәге күрсәтмәләре, ачыкланган җитешсезлекләрне юкка чыгару эшләренең исемлеген һәм күрсәтелгән эшләрнең сметасын теркәп. Җитешсезлекләрне бетерү буенча башкарылган эш турында хисап, раслаучы документларны (башкарылган эшләрнең актлары, исәп-хисап фактуралары) теркәп. | |
| 6.6 | Һәр кулланучы буенча фактик күләмнәрне күрсәтеп, хезмәтләрнең һәр төре буенча транспорт хезмәтләреннән файдаланучылар исемлеге. | |
| 7. | Транспорт чараларын техник карауны һәм техник карау талоны дубликатын бирүне гамәлгә ашыручы оешмалар өчен өстәмә. | |
| 7.1 | Техник карау үткәрү турында шартнамәләр. | РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 14.10.2011 № 573 боерыгы |
| 7.2 | Диагностика картасы, талон. | РФ Хөкүмәтенең 2011 елның 5 декабрендәге № 1008 карары |
| 8. | Халыкка социаль хезмәтләр күрсәтүче учреждениеләр өчен өстәмә. | |
| 8.1 | Күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеге. | |
| 8.2 | Түләүчеләр кисемендә хезмәтләрне теркәү журналы. | |
| 9. | Гомуми белем бирүче мәктәпләр, башлангыч, урта һәм югары һөнәри белем бирүче учреждениеләр каршындагы җәмәгать туклануы предприятиеләре өчен өстәмә. | |

| | | |
|---|---|---|
| 9.1 | Тикшерә торган чорга тормышка ашырылган (күрсәтелгән) продукция (хезмәтләр) ассортименты. | |
| 9.2 | Продуктлар, чимал китерүчеләр исемлеге. | |
| 9.3 | Оешма тарафыннан тикшерелә торган чорда туклану продуктлары өчен саналган калькуляцияләр, технологик карталар. | 27.06.2013 № 195-ст Росстандарт боерыгы |
| 9.4 | Тикшерә торган чорда хосусый җитештерү продукциясен әзерләү өчен кулланылган азык-төлек чималына керү документлары (исәп-хисап фактуралары, накладнаялар). | 25.12.1998 № 132 РФ Госкомстат карары;<br>РФ Хөкүмәтенең 2011 елның 26 декабрендәге № 1137 карары |
| 9.5 | Сатып алынучы, технологик яктан эшкәртмичә урнаштырыла торган товарларга килү һәм чыгу документлары. | |
| 10. | Гомер өчен зарури һәм әһәмиятле дару препаратлары исемлегенә кертелгән дару препаратларын да сатучы оешмалар өчен өстәмә. | |
| 10.1 | Сатылган дару препаратлары ассортименты. | |
| 10.2 | Дару препаратларын җиткерүчеләр исемлеге. | |
| 10.3 | Дару препаратларын китертүгә шартнамәләр төзелгән ваклап (күмәртәләп) сату оешмалары исемлеге. | |
| 10.4 | Сатып алу бәяләре турында, сату бәяләре турында, товар хәрәкәте турында белешмәләрне үз эченә ала торган килү һәм китү документлары (исәп-хисап фактуралары, накладнаялар, бәяләрне формалаштыру реестрлары). | 25.12.1998 № 132 РФ Госкомстат карары;<br>РФ Хөкүмәтенең 2011 елның 26 декабрендәге № 1137 карары;<br>РФ Хөкүмәтенең 2016 елның 3 февралендәге № 58 карары |
| 11. | Оешмалар тарафыннан элек тапшырылган, тарифларны хисаплаганда исәпкә алынган чыгымнарны нигезләүче документлар арасында барлыкка килгән төгәлсезлекләрне карау өчен кирәкле булган башка төрле документлар. | « |

2. Бу карар аны рәсми бастырып чыгарган көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Рәис М.Р.Зарипов